РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ

Нижнеалькеевского сельского поселения Алькеевского

муниципального района

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

Әлки муниципаль районы

Түбән Әлки авыл җирлеге

СОВЕТЫ

Адрес: 422881, РТ, с. Нижнее Алькеево, ул. Советская, д. 55

тел. 8 (84346) 77-2-15

Адресы: 422881, РТ, Түбән Әлки авылы, Совет ур., 55

факс: 8 (84346) 77-2-15

**РЕШЕНИЕ** Түбән Әлки авылы **КАРАР**

2024нче елның 13нче ноябре 69 №

2022елның " 14" декабрендәге Әлки муниципаль
Районы Түбән Әлки авыл җирлегенең
23 номерлы «Әлки муниципаль районы
Түбән Әлки җирле үзидарә
муниципаль берәмлегенең муниципаль хезмәткәрләре,
депутатларның, үз вәкаләтләрен даими нигездә
гамәлгә ашыручы үзидарәләрнең,
хезмәтенә түләү тәртибе һәм шартлары турында
нигезләмәне раслаутурында"гы
карарына үзгәрешләр кертү турында

2018нче елның 28нче мартындагы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә «Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең, депутатларның, җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы.

Сайланулы вазыйфаи затларның, рәисләрнең, рәис урынбасарларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары аудиторларының хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында"гы 182№ (2018нче елның 24 апрелендәге 281№, 2018нче елның 14нче июнендәге 481№, 2018нче елның 17нче октябрендәге 940№, 2018нче елның 29нчы декабрендәге 1320№, 2021нче елның 17нче ноябрендәге 1087№, 2021нче елның 13нче

декабрендәге 1222№, 2022нче елның 17нче сентябрендәге 1015№, 2024нче елның 30нчы апрелендәге 290№, 2024нче елның 24нче июнендәге 451№, от 2024нче елның 25нче сентябрендәге 829№ Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән),Әлки муниципаль районы Түбән Әлки җирле үзидарә Советы КАРАР КЫЛДЫ:

1.2022 елның 14 нче декабрендәге Әлки муниципаль районы Түбән Әлки авыл җирлеге Советының «Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, Әлки муниципаль районы Түбән Әлки авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәне раслау хакында» 23 номерлы карарына (2024 елның 16 маендагы 57 номерлы редакциядә) түбәндәгеләрне үзгәрешләрне кертергә:

4 пунктта түбәндәге абзац өстәргә:

01.01.2025 елдан Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Түбән Әлки авыл җирлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләме авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме белгеченең вазыйфаи оклады күләменә бер тапкыр исәпләнә, ул 13990 сум тәшкил итәчәк.

2. 1 нче кушымтаны кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

3.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматның http://pravo.tatarstan.ru.рәсми порталында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Әлки муниципаль районы
Түбән Әлки авыл җирлеге
Советы рәисе урынбасары

Ф.Ф. Мисалов

2024 нче елның 13 нче ноябрь
Әлки муниципаль районы
Түбән Әлки җирле үзидарә
Советының
69 нчы карарына
1нче кушымта

**2025НЧЕ ЕЛНЫҢ 1НЧЕ ГЫЙНВАРЕННАН ӘЛКИ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ ТҮБӘН ӘЛКИ ҖИРЛЕ ҮЗИДАРӘСЕНДӘ ДЕПУТАТЛАРНЫ, ҖИРЛЕ ҮЗИДАРӘНЕҢ ҮЗ ВӘКАЛӘТЛӘРЕН ДАИМИ НИГЕЗДӘ ГАМӘЛГӘ АШЫРУЧЫ САЙЛАНУЛЫ ВАЗЫЙФАИ ЗАТЛАРНЫ, ТҮБӘН ӘЛКИ ҖИРЛЕ ҮЗИДАРӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕК БАШЛЫГЫНЫҢ АЙЛЫК АКЧАЛАТА БҮЛӘКЛӘҮ КҮЛӘМНӘРЕ**

| Вазыйфаисеме | Айлык акчалата түләү күләмнәре (сумнарда) |
|---|---|
| | авылҗирлекләрендә |
| | 12 нчы төркем |
| Муниципаль берәмлек башлыгы | 19173 |
| Муниципаль берәмлек башлыгы урынбасары | 13 991 |
| Депутат | 13990 |
| Җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы | 13990 |